**СОВЕТ УСАДСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422710, Республика Татарстан, Высокогорский район, д.Тимофеевка ул. Профсоюзная, 45

**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УСАД АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422710, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Тимофеевка авылы, Профсоюз ур., 45

Тел./факс: +7(84365) 73-2-75, e-mail:Usad.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**03 ноября 2023г.** **№85**

**«Җир салымы турында» 2019 елның 12 ноябрендәге 194 номерлы Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Усад авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешенә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешендәге 78 статьясындагы 1 пунктының икенче абзацының гамәлдә булуын туктатып тору турында» 2023 елның 31 июлендәге 389-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Усад авыл җирлеге Советы нигезендә

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2019 елның 12 ноябрендәге «Җир салымы турында» Биектау муниципаль районының Усад авыл җирлеге Советы карарына (Совет карары редакциясендә: 30.04.2020 N 216, 16.06.2022 N 47, 27.10.2022 N 60, 25.11.2022 N 62) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Татарстан Республикасы башлыгы каршындагы Дәүләт резерв фонды милкендәге җир кишәрлекләренә карата 0,001 процент күләмендә;

2 пунктның 2 пунктчасының 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) «Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатларында махсуслаштырылган оешмалар милкендәге, Татарстан Республикасы башлыгы (Раис) вәкаләтле җир кишәрлекләренә карата 0,001 процент күләмендә;

2 пунктның 2 пунктчасындагы 2 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «-торак фонды һәм (яисә) торак-коммуналь комплексның инженерлык инфраструктурасы объектлары (торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган күчемсез мөлкәт объектына туры килә торган җир кишәрлегеннән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш);».

2. Әлеге карарны интернет челтәрендә «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында: https://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгару (халыкка җиткерү) юлы белән: http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы Р.Ф. Сибгатуллин